ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423747, Киров авылы,
Киров урамы, 52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

СОВЕТ КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

КАРАР РЕШЕНИЕ

13.11.2020 № 8

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Киров авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Киров авыл җирлеге Башлыгы:

Карар бирә:

1 2021 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарынан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны карап тоту, төзекләндерү, щебень, ком салу, кардан чистарту, тигезләү;

Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- Киров һәм Олы Имән авылларындагы зиратларны документлаштыру, агачлар кисү, территорияне төзекләндерү;

Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру:
- физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт, массакүләм чаралар оештыру һәм уздыру;

Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру;
- спорт мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу;
- авыл җирлеге территориясендәге агачларны кисү;
- хуҗасыз йортларны һәм биналарны бетерү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру;
- урам утларын урнаштыру, карап тору;

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү, карап тору, лицензияләү;
- янгын гидрантлары урнаштыру.

2. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге гражданнарының халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә

Киров авыл җирлеге советы рәисе И.Ф.Гаянов